**Тема:** “Сыйфатлар илендә”

(Сыйфат темасы буенча гомумиләштереп кабатлау)

Нәҗмиева Гөлнар Ленар кызы,“Күбәк урта гомуми белем бирү мәктәбе”нең беренче квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Аннотация

**Дәреснең уку курсындагы урыны 33 нче** дәрес « Сыйфат» бүлегенең 10 нчы дәресе. Моңа кадәр үзләштерелгән махсус белем һәм күнекмәләр: рус һәм татар телендәге сыйфатларны чагыштыру; сыйфат дәрәҗәләренең үзенчәлекләрен белү; асыл һәм нисби сый-фатларны аера белү; сыйфатларның җөмләдәге ролен билгеләү үзенчәлекләрен ачыклау; тамыр, ясалма, кушма, парлы, тезмә сыйфатларның ясалу үзенчәлеген белү; исемләшкән сыйфатларга хас билгеләрне аера белү; сыйфатларга морфологик анализ ясау;

Минем тематик планым нигезендә бу дәрестә үзләштерелергә тиешле махсус белем һәм күнекмәләр – предмет буенча планлаштырылган нәтиҗәлек: сыйфат темасы буенча белемнәрне системалаштыру.

**Дәреснең максатлары:**

1. Дидактик максаты: сыйфат темасын гомумиләштереп кабатлау.
2. Үстерешле максат: чагыштыру, гомумиләштерү кебек фикерләү күнекмәләре үсеше өчен шартлар тудыру.
3. Тәрбияви максат: морфология тармагы белән кызыксыну тудыру, белемле булу теләге тудыру.

**Планлаштырылган нәтиҗәлелек :**

1. **Предмет нәтиҗәлелеге:** сыйфат сүз төркеме турында белемнәрне тирәнәйтү, үткәннәрне ныгыту; сыйфатларның үзенчәлекләрен белү;

2. **Метапредмет нәтиҗәлелек:**
- **регулятив гамәлләр**: эшчәнлек барышын һәм нәтиҗәләрен тикшереп һәм бәяләп бару; рефлексия ясауда катнашу;
- **танып белү гамәлләре**: логик фикер йөртү, чагыштыру, анализ, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау;
- **коммуникатив гамәлләр**: партнер гамәлләре белән идарә итү , фикерне дөрес һәм төгәл итеп җиткерә белү, иптәшең белән аралашу әдәбе;

3. **Шәхескә кагылышлы (яки шәхес буларак үсешне күрсәтә торган) нәтиҗәлелек:** әйләнә-тирәдәгеләргә уңай мөнәсәбәт; әхлаклы булырга омтылу.

**Предметара бәйләнеш:** рус теле

**Дәреснең тибы:** йомгаклау-гомумиләштерү

**Танып белү эшчәнлеген оештыру методлары:** тикшерүле, өлешчә эзләнүле

**Танып белү эшчәнлеген оештыру формасы :** төркемнәрдә һәм индивидуаль эшләү

**Төп төшенчәләр:** асыл һәм нисби сыйфатлар, сыйфат дәрәҗәләре, сыйфат ясалышы, сыйфатларның җөмләдә кулланылышы, модель төзү.

**Ресурслар**

- **төп** : Татар теле. 6 нчы сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы/ Ф.Ю.Юсупов, Ч.М.Харисова, Р.Р.Сәйфетдинов. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2014.

Проектор, экран, ноутбук, аудиоязма, А3 форматындагы кәгазьләр, маркерлар, таймер, клей

- **өстәмә** : Татар теле дәресләре: Татар урта гомуми белем бирү мәкт. 6 нчы сыйныфында эшләүче укытучылар өчен методик кулланма / Р.Г.Хасаншина. – Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2009.

**Дәрес барышы**

**I. Ориентлашу- мотивлаштыру.**

**1) Уңай психологик халәт тудыру.**

**Максат:** дәрестә укучылар белән уңай атмосфера тудыру

Укытучы: Кереш сүз.Балалар, халкыбызның бик мәгънәле бер әйтемен искә төшерик әле.

“Тел дигән дәрья бар,
Төбендә энҗе- мәрҗән бар.
Белгәннәр чумып алыр,
Белмәгәннәр коры калыр.”
Мин дә сезне, белем дәрьясына чумып, андагы хәзинәләрне табарга чакырам.
Барыгыз да әзерме?

Укучылар: Әйе, без әзер.

**Көтелгән нәтиҗәлелек:**

**Танып-белү:** аңлап әйтеп бирү;

**Коммуникатив:** мәгълүмат җыю һәм эзләүдә инициативалы хезмәттәшлек;

**Шәхси:** татар теле дәресенә карата уңай мөнәсәбәт. Яхшы уку теләге формалаштыру.

**2) Мотивлаштыру.**
**Максат:** өй эшенә бирелгән видео аша теманы ачыклау.
Укытучы: Укучылар, мин сезгә үзенчәлекле өй эше биргән идем. Мин бу өй эше аша сезгә нәрсә әйтергә теләдем икән?
(Җаваплар тыңлана, дәреснең темасы ачыклана).
Укучылар: Ул видеода сыйфатларның роле, популярлыгы турында безнең мәктәп укучыларыннан сораштыру яздырылган иде. Димәк, без бүген сыйфатлар турында сөйләшүебезне дәвам итәрбез.

**Көтелгән нәтиҗәлелек:**

**Регулятив:** укучылар тарафыннан белгән күнекмәләрне үзара бәйләү;

**Танып-белү:** аңлап әйтеп бирү;

**Коммуникатив:** мәгълүмат җыю һәм эзләүдә инициативалы хезмәттәшлек;

**Шәхси:** укучының дәлилләре.

**3) Дәреснең максатын билгеләү. УМ кую.**
**Максат:** сыйфатны искә төшерү, төркемнәргә урнашу.
Укытучы: Димәк, без бүген нәрсә турында сөйләшербез, ни белән шөгыльләнербез?
Укучылар: Без инде сыйфатлар турында барысын да өйрәндек, тема буенча кабатлау дәресе үткәрербез.

Укытучы: Ә сыйфат турында без нәрсәләр беләбез соң?

Укучылар: сыйфат предметның билгесен белдерә, нинди? кайсы? кайдагы? сорауларына җавап бирә. Асыл һәм нисби сыйфатлар була. Сыйфат гади, чагыштыру, артыклык, кимлек дәрәҗәләрендә кулланыла ала. Ясалышы буенча тамыр, ясалма, кушма, парлы, тезмә сыйфатлар була. Сыйфат җөмләдә аергыч һәм хәбәр була ала.

Укытучы: Әйе, укучылар, бик дөрес. Бүген дә без сыйфат турында белемнәрне камилләштерүне дәвам итәрбез. Бу дәрестә төркемнәрдә эшләрбез, шуңа күрә башта төркемнәргә бүленербез. Мин 3 командага бүленергә тәкъдим итәм. Командирлар Ильяс, Рәилә, И.Ләйсән булырлар. Урыннарыгызны алыгыз.
(Төркемнәргә бүленү, урнашу).
**Предмет нәтиҗәлелеге:** Сыйфат турында белемнәрне актуальләштерү.

**Көтелгән нәтиҗәлелек:**
**Регулятив:** белгәннәр нигезендә ачыкланган белергә тиешле уку мәсьәләсен ачыклау.

**Танып-белү:** сыйфатның грамматик категорияләре турында кызыксынучан

лык;

**Коммуникатив:** сораулар куелышы, информация табу, иптәшеңнең үз-үзен тотышы белән идарә итү, фикереңне әйтә белү;

**Шәхси:** әхлаклы булырга омтылу.
**II. УМ чишү.**
1) **Модель төзү.**

**Максат:** туры килгән юнәлеш буенча, схемага нигезләнеп, белгәннәрне модель итеп формалаштыру.

Укытучы эшчәнлеге: һәр командага юнәлеш бирә, схема тәкъдим итә. Тактага яза.
1.Билгеләмә.
2.Аермалы билгеләре.
3.Мисаллар.
Таймер куша, вакытны контрольгә алырга киңәш итә. Талгын гына музыка куя. Укучылар эшчәнлеген күзәтә.
Укучылар эшчәнлеге: һәр төркем үзенә билгеләнгән юнәлеш буенча, схемага нигезләнеп, модель төзи:
1 төркем – сыйфат, аның төрләре турында;
2 төркем – сыйфат дәрәҗәләре, ясалышы ягыннан төрләре турында;
3 төркем – сыйфатларның җөмләдә кулланылышы һәм исемләшүе турында.
**Предмет нәтиҗәлелеге:**
Сыйфатларның морфологик үзенчәлекләрен һәм җөмләдә кулланылышын аңлау.

**Көтелгән нәтиҗәлелек:**

**Регулятив:** алдан фаразлау, контроль;

**Танып-белү:** синтез (кисәкләрдән бербөтен төзү); объектларны классификацияләү, чагыштыру өчен критерийлар сайлау; нәтиҗә чыгару; билге-символларны куллана белү (модельләштерү, модельне төрле формаларга китерү);

**Коммуникатив:** сораулар куелышы, фикереңне әйтә белү, тикшерү, коррекцияләү; төркемнәрдә эшләү;

**Шәхси:** укучының фикерләү сәләтен үстерү.

**2) Модельләрне тәкъдим итү.**

**Максат:** эшләгән моделеңне иптәшләреңә тәкъдим итәргә өйрәнү; сөйләм телен үстерү.

Укучылар эшчәнлеге: Һәр төркем башка төркемнәрнең эше белән танышып чыга. Һәр укучы үзенең йолдызын үзенә ошаган модельгә беркетә, бәя бирә.
Һәр төркем үзенең моделе белән таныштыра, аңлата, сөйли. Калганнары тыңлый, җитешсезлекләр булса төзәтә, әйтелеп бетмәгән фикерләрне өсти.
Укытучы эшчәнлеге:
Укучылар эшчәнлеген күзәтә, юнәлеш бирә. Чыгышларны тыңлый, хаталар булса төзәтә. Һәр модельне тактага беркетеп бара.

**Предмет нәтиҗәлелеге:** сүз төркемнәре турында информацияне дөрес куллану, сөйләм төзү күнекмәләрен үстерү.

**Көтелгән нәиҗәлелек:**

**Регулятив:** эшчәнлекнең дөрес үтәлешенә бәя бирә белү;

**Танып-белү эшчәнлеге:** гомум уку эшчәнлеге – үз фикереңне язма һәм сөйләмә рәвештә әйтә белү;

**Коммуникатив:** сөйләмне үз фикереңне төгәл әйтү өчен файдалана белү;

**Шәхси:** үз мөмкинлекләрен аңлап, үзенә дөрес бәя бирү. Үзеңне камилләштерү өстендә эшләргә кирәклекне аңлау; үз уңышларының һәм уңышсызлыгының сәбәпләрен ачыклау.

**3) Белемнәрне ныгыту, тикшерү.**

**Максат:** “сыйфат” темасы буенча белем үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү.

Укытучы: Укучылар, мин сезгә “Дөрес - дөрес түгел ” уены тәкъдим итәм (карточкалар өләшә), дөрес дип уйлаган аңлатма янына “+” тамгасы, дөрес түгел дигәненә “-” тамгасы куярсыз. Башладык.

Укучылар биремне башкарганнан соң, иңсәгә-иңсә партнерлар белән эшләрен алмашалар. Ни өчен шундый тамгалар куюны дәлилиләр, дөреслеген тикшереп, бәя куялар.

**Предмет нәтиҗәлелеге:** “Сыйфат” темасы буенча белем дәрәҗәсен ачыклау.

**Көтелгән нәтиҗәлелек:**

**Регулятив:** алдан фаразлау, контроль , үзбәя бирергә өйрәтү;

**Танып-белү:** мәсьәләне чишү өчен тамга-символик чаралар куллану;

**Шәхси:** укуга уңай караш. Укучыларда мөстәкыйльлек тәрбияләү.

**III. Рефлексия.**

**Максат:** дәрестәге эшчәнлекне анализлау.

Укытучы: Бу дәрестә нәрсәләр белән шөгыльләндек? Дәрес сезгә ошады

мы? Дәрес турында фикерләрегезне 1 сыйфат белән әйтеп карагыз әле.

Укучылар фикерләрен җиткерәләр, чылбыр буенча җавап бирәләр.

**Көтелгән нәтиҗәлелек:**

**Регулятив:** эшчәнлеккә объектив бәя бирә белү;

**Танып-белү:** алган белемнең куллану өлкәсен күзаллый белү;

**Коммуникатив:** фикерне тулы итеп әйтә белү;

**Шәхси:** мәгънә төзелеше, укучының дәлилләре.

1) **Өй эше.**

1. “Сабантуй”, “Көмеш кыңгырау” газеталарыннан сыйфатлар кергән 5 җөмлә язып алырга.

2.“Сыйфат” темасы буенча тест төзергә.

3.Сыйфатлар кулланып, көзге урманны тасвирларга. Электрон почтаны карарга.

**2) Йомгаклау.**

Укытучы: Укучылар, сез бүген бик тырыштыгыз, актив булдыгыз, рәхмәт сезгә. Ә хәзер дәрестәге эшчәнлекне бәяләү өчен “Чыгу билеты” тәкъдим итәм.

Укучылар билетларны тапшыралар һәм чыга баралар.

Укытучы: дәрес тәмам. Чыгарга мөмкин. Сау булыгыз.

**Көтелгән нәтиҗәлелек:**

**Шәхси:** укучы дәрестә үзенең нәрсә белүен ачыклый, нәтиҗә ясый.